Автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Чүпрәле муниципаль районы Уставына таянып, Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясында билгеләнгән Чүпрәле муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкаларны (парковка урыннарын) булдыру һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану өлкәсендә башка вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренә тапшыру.

2. Чүпрәле муниципаль районы башлыгына әлеге Карарның 1 пункты нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында Чүпрәле муниципаль районы исеменнән авыл җирлекләре белән килешү төзүне йөкләргә.

3. Әлеге Карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Чүпрәле муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган финанс чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Советы Рәисе: А.В. Шадриков